ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.05 2022 ел Баулы шәһәре №90

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Кредит акчаларын кулланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны балигъ булмаганнар катнашында залогка (ипотекага) тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 3 июлендәге 201 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Кредит акчаларын кулланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны балигъ булмаганнар катнашында залогка (ипотекага) тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 3 июлендәге 201 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләр кертергә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән» сүзләрен преамбулада төшереп калдырырга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

2 нче «муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5. пунктының икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Ике ата-ананың да (яисә аларны алмаштыручы затларның гаризасы (административ регламентка 1 нче кушымта);

2. законлы вәкил ризалыгы белән эш итүче 14 яшьтән 18 яшькә кадәр балигъ булмаган баланың гаризасы;

3. ата-аналар паспортлары (яки аларны алмаштыручы затларның);

4. балигъ булмаган бала паспорты;

5. сатып алынган фатирга хокук билгели торган документлар (хосусыйлаштыру килешүе, сату-алу килешүе һ. б.);

6. сатучы сатуга гариза-ризалыгы;

7. сатып алына торган фатирның техник паспорты (БТИ белешмәсе);

8. ана (гаилә) капиталына сертификат һәм индексация турында белешмә (ана капиталы акчаларын җәлеп итү кирәк булганда);

9. чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе (булганда);

10. Граждан хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык.

Документларның оригиналлары һәм күчермәләре тапшырыла, нотариаль расланган документларның күчермәләрен кабул итү мөмкин.»;

2.6. пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“күчемсез милек объектына бердәм дәүләт реестрыннан өземтә»;

3 нче бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерак урнашкан эш урыннарында административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гузаиров